Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы
Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пункты
территориясенең бер өлешендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2023 елның 12 декабре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 12 декабрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты өлеше территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2024 елда 7100 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:
-Урман, Майская, Яшьләр урамнары буйлап юлларны кышкы чорда карап тотуга (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тыкырыктан алып Майская урамындагы 39 йортка кадәр суүткәргеч төзүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Майская урамындагы 32 нче йорттан 34 нче йортка кадәр территорияне төзекләндерүгә (бетон сатып алу һәм китерү, декоратив агачлар һәм газон үләннәре утырту);
Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлегенең Майская Горка авылы торак пунктында гражданнар җыенын 28.11.2020 елның 2 номерлы карары нигезендә гражданнарның җыелган үзара салымнарын буаны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); чишмәне төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә (уен балалар җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру) - 33800 сум күләмендә, Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә.

ӘЙЕ ЮК»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 12 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 12 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Майская Горка авыл җирлеге составына керүче Майская Горка торак пункты өлешендәге гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлеге Майская Горка торак пункты өлеше территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2024 елда 7100 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урман, Майская, Яшьләр урамнары буйлап юлларны кышкы чорда карап тотуга (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тыкырыктан алып Майская урамындагы 39 йортка кадәр сууткәргеч төзүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерүгә (материал сатып алу һәм китерү, экскаватор эше, килешүбуенча эшләр өчен түләү);
- Майская урамындагы 32 нче йорттан 34 нче йортка кадәр территорияне төзекләндерүгә (бетон сатып алу һәм китерү, сатып алу, китерү, декоратив агачлар һәм газон үләннәре утырту);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Майская Горка авыл җирлегенең Майская Горка авылы торак пунктында гражданнар җыенын 28.11.2020 елның 2 номерлы карары нигезендә гражданнарның җыелган үзара салымнарын буаны төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); чишмәне төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү); балалар мәйданчыгын төзекләндерүгә (уен балалар җиһазларын сатып алу һәм урнаштыру) - 33800 сум күләмендә, Майская Горка торак пунктында чишмәләрне төзекләндерүгә (килешү буенча эшләр өчен түләү) юнәлдерергә мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Майская Горка авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Майская Горка авыл җирлеге башлыгы А.П. Морозов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЙСКО-ГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НИЖНЕКАМСКИЙ РАЙОН ОГРН 1061651024104 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА РАЙОНЫ ИНН 1651045243